Раслыйм
МБОУ «СОШ №1» НМР РТ
О.В.Корытова

**Татарстан Республикасы**
**Түбән Кама шәһәре**
**“Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче**
**1 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе”**
**Муниципаль белеем бирү учреждениесенең**
**2020-2021 нче уку елына**
**милли мәгарифне үстерү планы**

**Максат:**

Баланың сәләтен барлау, ачу, үстерү, аны шәхси үсеш траекториясенә лаек дип табу, милли һәм гомумкешелек казанышларына таянып уку-укыту эчтәлегенә үзгәрешләр кертү.

**Бурычлар:**

1. Яңа дәүләт уку-укыту стандарты проектын өйрәнү, гамәлгә ашыру өстендә эшләү.
2.Гимназия шартларында дәүләт стандартларын уңышлы үзләштерүче, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, милли үзаңлы, сәләтле, иҗади шәхес формалаштыру
3. Укучыларга татар телендә белемнәрне үзләштерү, үсү һәм аны куллану өчен психологик, педагогик шартлар тудыру.
4. Заманча мәгълүмати технологияләр үсеше шартларында, укучыларга индивидуаль якын килеп, укучы һәм укытучының үзбилгеләнүләрен формалаштыру.
5. Һәр укучыга үзүсеш һәм уку траекториясен төзергә мөмкинлекләр тудыру.
6. Укучыларны фәнни-эзләнү эшләренә җәлеп итү өчен уку эчтәлеген һәм оештыру формаларын эзләү.
7. Укучыларның үзешчән җәмәгать оешмаларын формалаштыру өчен материаль һәм фәнни нигез булдыру.
8. Уку-укыту процессын индивидуальләштерү өчен уку планының вариатив өлешен камилләштерү.
9. Бүгенге таләпләргә туры китерү өчен материаль-техник базаны үстерү өстендә эшләү (интерактив такталар, Интернетка беркетелгән компьютерларның бердәм челтәрен булдыру, библиотека фондын фәнни-популяр, методик әсбаплар һәм дәреслекләр белән тулыландыру).
10. Уку-укыту процессының сыйфат мониторингын булдыру.
11. Укучыларның белемен бәйсез комиссия ярдәмендә аттестацияләү системасын камилләштерү өстендә эшләү.
12. Укытучыларның профессиональ осталыкларын күтәрү.
13. Шәһәр һәм республика югары уку йортлары белән тыгыз элемтәдә эшләү.
14.Милли үзаң формалаштыру ысулларын камилләштерү өстендә эшләү.
15. Тарихи – мәдәни мирас елына багышланган бәйләнешле чаралар уздыру.

| № | Эшнең эчтәлеге | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Яңа уку елына мәктәпне педагогик кадрлар белән комплектлау. | август | Корытова О.В. |
| 2. | Беренче ,бишенче һәм унынчы сыйныфларга балалар туплау. | август | Корытова О.В.<br>Хамбалова Э.Х. |
| 3. | Укучыларның (1-11нче сыйныфка кадәр) татар телендә белем алуларын тәэмин итү. | ел буена | Корытова О.В.<br>КузнецоваН.В.<br>Хамбалова Э.Х. |
| 4. | Укучыларга төп һәм урта белем бирүне тәэмин итү. | ел буена | администрация |
| 5. | Башлангыч сыйныф һәм фән кабинетларын җиһазлауны дәвам итү. | ел буена | кабинет мөдирләре |
| 6. | Татар телендә эшләүче түгәрәкләр ачу, аларның эшләвен тәэмин итү. | ел буена | Хамбалова Э.Х. |
| 7. | Китапханәне дәреслекләр, матур әдәбият, сүзлекләр, укыту әсбаплары, методик кулланмалар белән тәэмин итү эшен дәвам итү.Китапханәнең татар һәм рус телләрендә чыга торган газет-журналларга язылуын контрольдә тоту.Электрон китапханә һәм татар сайтлары, медиатека булдыру өстендә эш. | даими | Администрация<br>Мухамадиева А.З. |
| 8. | Педагогик кадрларның профессиональ осталыкларын яхшырту һәм хезмәткә мотивацияне күтәрү өстендә эшләү. | даими | администрация |
| 9. | Педагогик кадрлар әзерләү буенча Түбән Кама педагогия колледжы,Алабуга педагогик университеты һәм Яр Чаллы ӨПББ институты белән хезмәттәшлекне яхшырту. | даими | администрация |
| 10. | Педагогик эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген үлчәү методикасын модернизацияләү. | даими | администрация |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Түләүле укыту - тәрбия хезмәте күрсәтү механизмын яхшырту | ел буена | администрация |
| 12. | Мәктәпнең материаль-техник базасын яхшырту. | ел буена | администрация |
| 13. | Җитәкчелекнең нәтиҗәлелеген күтәрү. | даими | администрация |
| **II."Татарстан халыклары телләре" турындагы Законны гамәлгә ашыру өстендә эш.** | | | |
| 1. | РФ һәм ТРның «Белем бирү турындагы» Кануннарын, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турындагы Татарстан Республикасы Законы»н тормышка ашыруга нигезләнеп,татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыту планы нигезендә алып бару. | ел буена | администрация |
| 2. | Мәктәптә документлар язуны ике телдә алып бару. | ел буена | администрация |
| 3. | Әхлак тәрбиясе бирүне сыйныф сәгатьләрендә, чараларда, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты дәресләрендә оештыру. | ел буена | администрация |
| 4. | Мәктәптә татар телендә яңа стендлар булдыру. | даими | администрация |
| 5. | Татар теленең кулланылышын арттыру максатында укыту-тәрбия сыйфатын күтәрү:<br>- башлангыч сыйныфларда телгә мәхәббәт уяту, халык педагогикасына нигезләнеп тәрбияләү;<br>- профильле укытуны дәвам итү;<br>- укытучыларның профессиональ осталыклары өстендә эшләү, башлангыч сыйныфларда "дәрестә уку эшчәнлеген оештыру" технологиясе буенча эшне дәвам итү;<br>- сәләтле балалар белән фәннәрне тирәнтен өйрәнү, фән бәйгеләренә әзерләү, фәнни-эзләнү эшләрен оештыру, өстәмә белем бирү дәресләрендә төрле яклап үстерү;<br>- зыялы, тирән белемле балалар тәрбияләүгә җәмәгатьчелекне, әти-әниләрне җәлеп итү;<br>- һәр баланың шәхси үсеш траекториясен төзү өстендә эшләү;<br>- уку-укыту процессының белем сыйфаты мониторингын булдыру;<br>- укучыларның белемен бәйсез комиссиядә аттестацияләү системасын булдыру. | даими | администрация |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Сәламәт,тәрбияле,белемле милләт тәрбияләү максаты белән<br>“Үсеш” программасы буенча эшләү. | ел буена | администрация |
| 7. | Укыту-тәрбия процессын информатизацияләү, татар программалары булдыру, медиатеканы киңәйтү. | ел буена | администрация |
| 8. | Музыка, рәсем, технология дәресләрендә татар композиторларын, рәссамчыларны, сәнгать кешеләрен өйрәнүне киңәйтү. | ел буена | Хамбалова Э.Х.<br>Седлова Е.В. |
| | **III. Укыту-тәрбия эшенең сыйфатын күтәрү.** | | |
| 1. | Укыту программаларына федераль һәм региональ компонент өстенә гимназия компонентын кертү, раслау. | август | администрация |
| 2. | Укыту-тәрбия календарь-тематик планнарны тикшереп раслау. | август | администрация |
| 3. | Норматив документларның (РФ һәм ТРның «Белем бирү турындагы» Кануннарын, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турындагы Татарстан Республикасы Законы»н тормышка ашыруга нигезләнеп) өйрәнелүен һәм эштә кулланылышын тәэмин итү. | даими | администрация |
| 4. | Дәресләр, түгәрәкләр тәртибен СанПиНга туры китереп төзү. | сентябрь | администрация |
| 5. | Кабинетларны техник чаралар, күргәзмә әсбаплар белән тәэмин итү. | ел буена | администрация |
| 6. | Укытучыларның сәләтле балалар белән эш планнарын тикшереп раслау. | сентябрь | администрация |
| 7. | Баланың табигый сәләте буенча укыту-тәрбия эше оештыру, дифференциаль укыту. | ел буена | администрация |
| 9. | Һәр укучының белем дәрәҗәсен анализлаган мониторинг булдыру (портфолиода). | ел буена | администрация |
| 10. | Уку процессында информацион технологияләрне киңрәк куллану. | ел буена | администрация |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Интерактив, уку эшчәнлеген оештыру алымнарын киң кулланылышка кертү, укытучыларны әзерлек курсларында укыту. | ел буена | администрация |
| 12. | Информатиканы 3нче сыйныфтан, чит телен 2нче сыйныфтан, шахмат 2 сыйныфтан кертү, 4 нче сыйныфларга “Диннәр мәдәнияты һәм дөньяви этика нигезе” фәнен кертү. | ел буена | администрация |
| 13. | Фән бәйгеләрен 2-11 нче сыйныфларда үткәрү, шәһәр бәйгеләренә әзерләү. | ел буена | администрация укытучылар |
| 14. | Халыкара туган көне кысаларында татар теле декадасы уздыру. | февраль | администрация укытучылар |
| 15. | Педагогик киңәшмәләр уздыру. | чирек саен | администрация |
| 16. | Шәһәр администрациясе башлыгы грантына, “Иң яхшы укытучы” грантына, “Ел укытучысы”, “Ел хатын - кызы” бәйгесенә һ.б. укытучыларны әзерләү, катнашу. | ел буена | администрация |
| 17. | Башлангыч сыйныф һәм фән кабинетлары арасында бәйге уздыру. | март | методкиңәшмә |
| 18. | Укучыларның фәнни оешмасында эшне киңрәк җәелдерү. | ел буена | администрация укытучылар |
| | **VI.Милли тәрбия бирү.** | | |
| 1. | Татарстанның бәйсезлегенә, РФ һәм ТР конституцияләренә, Бөтендөнья мөселманнар көненә, хәтер көненә, халык бердәмлеге көненә багышланган сыйныф сәгатьләре, татар әдәбияты дәресләрен уздыруны контрольдә тоту. | даими | администрация укытучылар |
| 2. | Шәһәр күләмендә уздырыла торган халык бәйрәмнәрендә катнашу:<br>- Сөмбелә,<br>- Нардуган,<br>- Сабантуй. | көз яз җәй | администрация укытучылар |
| 3. | Истәлекле даталарны билгеләп үтү. | даими | администрация укытучылар |
| 4. | Тарихи – мәдәни мирас елына багышланган бәйләнешле | ел буена | администрация |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чаралар уздыру | | укытучылар |
| 5. | Радиотапшырулар оештыру, гимназия сайтына мәгълүматны татар телендә язу. | ел буена | администрация |
| 6. | Шәһәр күләмендә уздырыла торган “Чибәркәй”, “Татар егете”, “Көйле,моңлы татар җыры”, “Р.Вәлиев бәйгесе”, “Г.Тукай шигырьләрен яттан сәнгатьле сөйләү” һ.б. бәйгеләрдә катнашу. | ел буена | Хамбалова Э.Х |
| | **V. Кадрлар белән эш.** | | |
| 1. | Мәктәптә кадрлар белән комплектлау. | август | Корытова О.В. |
| 2. | Укытучыларны белемнәренә, эш стажларына, мөмкинлекләренә карап һәм укыту эшендә дәвамчанлыкны тәэмин итүне күздә тотып, төрле сыйныфларга беркетү. | август | Корытова О.В. |
| 3. | “Аттестация узучылар атналыгы” үткәрү. | ел буена | Кузнецова Н.В. |
| 4. | Методик берләшмә планын кабул итү, раслау. Методик берләшмә утырышларын уздыруны контрольдә тоту. | ел буена | администрация |
| 5. | Ачык дәресләр күрсәтүне, үзара дәресләргә йөрүне оештыру, контрольдә тоту. | ел буена | администрация |
| 6. | Фәннәр укытуның сыйфатын яхшырту максаты белән укытучыларның профессиональ осталыкларын күтәрү, хезмәт дисциплинасын үтәү өстендә эш. | ел буена | администрация |
| 7. | Үз эшләрендә югары уңышларга ирешкән укытучыларны материаль яктан бүләкләү критерийларын карау,квартал саен өстәмә дифференциаль түләү. | ел буена | администрация |
| 8. | ШМИсенә мактау кәгазьләре белән бүләкләү өчен тәкъдимнәр бирү. | ел буена | администрация |
| | **VI.Ата-аналар белән эш.** | | |
| 1. | Попечительләр белән эш планын язу, кабул итү. Ата-аналар җыелышлары уздыру. | сентябрь | Корытова О.В. Седлова Е.В. |
| 3. | Ата-аналар белән берлектә “Әти, әни һәм мин – спорт | ел буена | Хамбалова Э.Х. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яратучы гаилә","Дөрес туклану –сәламәтлек нигезе", "Туган көннәрне бергә уздырабыз!" һ.б.бәйрәмнәрен уздыру. | | |
| 4. | 1нче сыйныф әти-әниләрен план буенча укытуны оештыру. | ел буена | Хамбалова Э.Х. |
| 5. | Еллык отчет-ижади концерты күрсәтү. | май | Абзалова Г.Н. |
| 6. | Булачак 1нче сыйныф укучыларының әти-әниләре өчен лекторий оештыру. | февраль, март | Кузнецова Н.В. |
| | **VII.Микрорайон белән эш.** | | |
| 1. | № 3,13 нче балалар бакчалары белән дәвамчанлык принцибы буенча эшне дәвам итү. | ел буена | Кузнецова Н.В. |
| 2. | Өлкәннәр һәм Укытучы көне, Гаилә бәйрәмнәрендә укытучы ветераннар белән, әби-бабайлар белән сыйныф сәгатьләрендә очрашулар системасын булдыру. | ел буена | Седлова Е.В. |
| | **VIII.Матди базаны ныгыту** | | |
| 1. | Кабинетларны бүгенге көн таләпләренә туры китереп җиһазлауны таләп итү ( күрсәтмә әсбаплар, җиһазлар, техник чаралар, яшелләндерү ). | ел буена | Корытова О.В. Хусаинова Г.Р. |
| 2. | Китапханәдә методик әсбаплар, дәреслекләр, матур әдәбият туплау; медиатеканы тулыландыру. Вакытлы матбугатка язылуны оештыру. | ел буена | Корытова О.В. Мухамадиева А.З. |
| 3. | Шефлар белән тыгыз элемтәдә эшләү, спонсорлыкка җәлеп итү. | ел буена | Корытова О.В. |

Төзеде
милли эшләр буенча
җаваплы директор урынбасары Э.Х.Хамбалова